| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.07.2024 Казан ш. № 414-пр

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясе турында нигезләмәне раслау турында**

«Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79–ФЗ Федераль законга, "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законга, “Федераль дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссияләр турында” Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге № 821 Указы, «Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законга, “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәве һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссияләр турында” Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы № УП-569 Указы нигезендә боерам:

1. Беркетелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясе турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата

таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссия составы.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясе турында нигезләмәне раслау турында” 23.03.2016 № 132-пр боерыгын, “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 23.03.2016 № 132-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында” 21.12.2017 № 607-пр боерыгын, “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2016 елның 23 мартындагы № 132-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 27.09.2022 № 580-пр боерыгын, “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясе турында нигезләмәне раслау турында” Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 23.03.2016 № 132-пр боерыгына үзгәрешләр кертү турында” 07.09.2023 № 633-пр боерыгын көчен .галткан лип таныргa.

3. Әлеге боерыкның үтәлеген контрольдә тотуны Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары А.А.Киямовка йөклим.

**Министр** **А.Р.Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
____________№___________
боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79–ФЗ Федераль законга, "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законга, “Федераль дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссияләр турында” Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге № 821 номерлы Указы, «Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законга, “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссияләр турында” Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы № УП-569 номерлы Указы нигезендә эшләнгән. Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясен (алга таба – Комиссия) формалаштыру тәртибе һәм аның эшчәнлеге билгеләнә.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм бу Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссиянең төп бурычы булып түбәндәгеләргә булышу тора:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре, Министрлык) чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне, шулай ук, алар тарафыннан "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль закон, башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларның (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр) үтәлешен тәэмин итү;

Министрлыкта коррупцияне кисәтү чараларын тормышка ашыру.

1.4. Комиссия Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренә, дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүчеләргә (алга таба – дәүләт хезмәте вазифалары) мөнәсәбәтле хезмәт тәртибенә кагылышлы таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлешенә бәйле мәсьәләләрне карый (билгеләү һәм азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарылучы дәүләт хезмәте вазифасын биләүче дәүләт хезмәткәрләре чыгарылма булып тора).

1.5. Билгеләү һәм азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарылучы, Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифасын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә мөнәсәбәтле хезмәт тәртибенә кагылышлы таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлешенә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында оештырылган хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясе тарафыннан карала.

1.6. Комиссия җинаять һәм административ хокук бозулар турында хәбәрләрне, шулай ук, аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр уздырмый.

## II. Комиссия составы

2.1. Комиссия составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифаларын биләүче комиссия әгъзалары арасыннан министр тарафыннан билгеләнгән Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, сәркатип һәм Комиссия әгъзалары керә. Комиссиянең барлык әгъзалары карар кабул иткәндә тигез хокуклы. Комиссия рәисе югында аның бурычларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) министр урынбасары (Комиссия рәисе), Министрлыкның кадрлар бүлеге һәм дәүләт хезмәте бүлегенең коррупцияне һәм башка хокук бозуларны кисәтү эшенә җаваплы вазифаи заты (Комиссия сәркатибе), Министрлыкның кадрлар бүлеге, хокук идарәсе, Министрлыкның министр билгеләгән башка бүлекчәләре дәүләт хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Рәисе Аппаратының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча вәкиле һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләре буенча бүлекчәсе вәкиле;

в) эшчәнлеге дәүләт хезмәте белән бәйле фәнни оешмалар, һөнәри мәгариф оешмалары, югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирүче мәгариф оешмалары вәкиле (вәкилләре).

2.3. Министр комиссия составына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карамагындагы Иҗтимагый совет, Министрлыкның башлангыч профсоюз оешмасы һәм Ветераннар Советы вәкилләрен кертү турында карар кабул итә ала.

2.4. Нигезләмәнең 2.2. пунктындагы "б" һәм "в" подпунктларында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына билгеләнгән тәртиптә министр запросы буенча тиешле органнар һәм оешмалар белән килешеп кертелә.

2.5. Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифасын биләмәгән Комиссия әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми санының дүрттән береннән дә ким булмаска тиеш.

2.6. Комиссия составы Комиссия тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырдай мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

2.7. Комиссия утырышларында тавышы киңәш бирү хокукында булган түбәндәгеләр катнаша:

а) Комиссия тарафыннан аңа мөнәсәбәтле хезмәт тәртибенә кагылышлы таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше каралган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе, һәм Министрлыкта Комиссия тарафыннан эше каралган дәүләт хезмәткәренә охшаш вазифалар биләгән Комиссия рәисе билгеләгән ике дәүләт хезмәткәре;

б) Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифаларын биләүче башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча һәм комиссия караган мәсьәлә буенча ачыклык кертә алган белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының вазифаи затлары; мәнфәгатьләре булган оешма вәкилләре; аңа мөнәсәбәтле хезмәт тәртибенә кагылышлы таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше каралган дәүләт хезмәткәренең вәкиле – Комиссия рәисе карары буенча, һәр аерым очракта Комиссия утырышана өч көн алда Комиссия тарафыннан эше каралган дәүләт хезмәткәре яки Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасы тарафыннан бирелгән ходатайство нигезендә.

2.8. Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан өчтән икесеннән дә ким булмаган санда кеше катнашса, Комиссия утырышы хокуклы дип санала. Утырышны Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифасын биләүче әгъзалар белән генә уздырырга ярамый.

2.9. Комиссия әгъзасының Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәлә буенча турыдан туры яки читләтеп шәхси мәнфәгате килеп чыккан очракта ул утырыш башланганчы бу хакта хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта әлеге Комиссия әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне карауда катнашмый.

## III. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия утырышын үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) дәүләт хезмәткәрләре биргән белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсе һәм дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт урынындагы тәртибе таләпләренең үтәлеше буенча түбәндәгеләр булганда министр тәкъдиме:

Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге № УП-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва иткән гражданнарга үз керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында Нигезләмәдә каралган белешмәләрнең дәүләт хезмәткәре тарафыннан дөрес һәм тулы тапшырылмавы;

дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә кагылышлы таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәмәве;

б) кадрлар бүлегенә Министрлыкның норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрнең керүе:

Министрлык боерыгы белән расланган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә кергән дәүләт хезмәте вазыйфасын башкаручы гражданинның әгәр дә бу оешма белән дәүләт идарәсенең аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерцияле яки коммерциячел булмаган оешмада хезмәт килешү шартларында вазыйфа биләргә яисә коммерцияле яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкарырга ризалык бирүе турында мөрәҗәгате, дәүләт хезмәтеннән киткәннән ике ел узганчы;

министрлыкның дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр буенча хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында әлеге Тәртипнең кушымтасына туры китереп белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмавы турында гариза;

чит ил территориясендә булган счетлар (кертемнәр), чит ил банкында сакланган акчалар һәм кыйммәтле әйберләр һәм чит ил финанс инструментлары чит дәүләт законнары нигезендә чит дәүләт компетентлы органнары карары белән тыелуы, кулга алынуы сәбәпле, яки аның үзеннән яисә хатыныннан (иреннән) һәм балигъ булмаган балаларыннан тормаган шартлар аркасында, әлеге Тәртипнең кушымтасына туры китереп, “Затларның аерым категорияләренә Россия Федерациясе территориясе чикләрендә чит ил банкларында счет (кертем) ачарга һәм ия булырга, чит ил банкларында акча һәм кыйммәтле әйберләр сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) кулланырга тыелу турында” 2013 елның 7 маендагы № 79-ФЗ Федераль законы таләпләрен үтәү мөмкин булмавы турында Министрлык дәүләт хезмәткәренең гаризасы;

дәүләт гражданлык хезмәткәренең вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерердәй яки китерә алган шәхси мәнфәгатьләре барлыкка килүе турында белдерүе;

в) министрның яки Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибен һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәвен тәэмин итүгә кагылышлы яисә Министрлыкта коррупцияне кисәтү чараларын тормышка ашыру тәкъдиме;

г) министрның дәүләт хезмәткәренең "Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында" Федераль законның 3 статьясының 1 кисәгендә каралган белешмәләрне дөрес бирмәвен яки тулы бирмәвен дәлилләгән тикшерү материалларын тәкъдим итүе;

д) "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль законның 12 статьясының 4 кисәгенә һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64[1] статьясына туры китереп Министрлыкка коммерцияле яки коммерциячел булмаган оешмадан Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифасын биләгән гражданин белән эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый килешүе турында белдерү керсә, әлеге оешма белән дәүләти идарәнең кайбер функцияләре министрлыкта вазифа биләүченең вазифаи (хезмәт) бурычы булып саналса, күрсәтелгән гражданинга Комиссия тарафыннан әлеге оешма белән хезмәт яки гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә керүдән баш тартылган булса яисә Комиссия тарафыннан бу гражданинга коммерцияле яки коммерциячел булмаган оешмада вазифа биләү яисә коммерцияле яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкарырга рөхсәт бирү мәсьәләләре каралмаган булса;

е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә кагылышлы таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәргә комачаулаган аннан тормаган шартлар китилеп чыгуы турында белдерүе.

3.2. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының “б” подпунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифасын биләгән граждан тарафыннан Министрлыктагы кадрлар бүлегенә тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны буенча адресы, дәүләт хезмәтеннән киткән көнгә кадәрге соңгы ике ел дәвамында биләгән вазифалары, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешманың аталышы, урнашкан урыны, аның эшчәнлек итү характеры, гражданның аның тарафыннан дәүләт хезмәте вазифасын биләү вакытында башкарылган вазифаи (хезмәт) бурычлары, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмага карата дәүләт идарәсе буенча функцияләр, шартнамә төре (хезмәт яки гражданлык-хокукый), күзалланган гамәлдәге вакыты, шартнамә буенча эшләр (хезмәтләр) башкаруга (күрсәтүгә) түләү суммасы. Кадрлар бүлегендә мөрәҗәгать карап тикшерелә, аның нәтиҗәсендә, “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең асылы буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

3.3. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының “б” подпунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать үзенең дәүләт хезмәтеннән китүен планлаштыручы дәүләт хезмәткәре тарафыннан бирелергә мөмкин һәм Комиссия тарафыннан бу Нигезләмә нигезендә карап тикшерелергә тиеш.

3.4. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының “д” подпунктында күрсәтелгән белдерүнамә Министрлыктагы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазифаи заты тарафыннан карап тикшерелә, ул Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифасын биләгән граждан тарафыннан “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законның 12 статьясындагы таләпләрнең үтәлеше турында дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

3.4.1. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының “б” подпунктының бишенче абзацында һәм «е» подпунктында күрсәтелгән белдерүнамә Министрлыктагы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазифаи заты тарафыннан карап тикшерелә, ул белдерүнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмә әзерли.

3.4.2. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының “б” подпунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яки шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының “б” подпунктындагы бишенче абзацында һәм «е» һәм “д” подпунктларында күрсәтелгән белдерүнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмә әзерләгәндә Министрлыкның кадрлар хезмәтенең вазифаи затлары мөрәҗәгатьне яки белдерүнамәне җиткергән дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә үткәрергә һәм аннан язмача аңлатмалар алырга хокуклы. Мәгълүмат алу өчен Министрлык билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга запрослар җибәрә, коррупциягә каршы тору өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасын куллана ала, шул исәптән запрослар юллар өчен дә. Мөрәҗәгать яки белдерүнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки белдерүнамә кергән көннән алып җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Запрослар җибәрелгән очракта мөрәҗәгать яки белдерүнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки белдерүнамә кергән көннән башлап 45 көн дәвамында тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт Комиссия рәисе тарафыннан 30 көннән артмаган чорга озынайтылырга мөмкин.

3.4.3. Бу Нигезләмәнең 3.2, 3.4, 3.4.1 пунктларында күрсәтелгән нигезле бәяләмәләр түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) бу Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» подпунктындагы икенче һәм бишенче абзацларда һәм «д» һәм «е» подпунктларында күрсәтелгән, мөрәҗәгатьтә һәм белдерүнамәләрдә бәян ителгән мәгълүматны;

б) запрослар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүматны;

в) бу Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» подпунктындагы икенче һәм бишенче абзацларда һәм «д» һәм «е» подпунктларында күрсәтелгән, мөрәҗәгать һәм белдерүнамәләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча нигезле нәтиҗәләр, шулай ук, бу Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18, 3.19 пунктларына туры килгән карарларның берсен яки башка карар кабул итү өчен рекомендацияләр.

3.5. Комиссия утырышын үткәрү өчен нигезләрне үз эченә алучы мәгълүмат килеп ирешкәндә, Комиссия рәисе:

а) 10 көн эчендә Комиссия утырышы датасын билгели. Шушы Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында каралган очраклардан тыш, Комиссия утырышының көне күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән башлап 20 көнгә соңга калып билгеләнә алмый;

б) аңа карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә карап тикшерелүче дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында катнашучы башка затларны кадрлар бүлегенә килеп ирешкән мәгълүмат һәм аны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) шушы Нигезләмәнең 2.7 пунктының “б” подпунктында күрсәтелгән затларны Комиссия утырышына чакыру турында үтенечнамәләрне карап тикшерә, аларны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карап тикшерү турында (карап тикшерүдән баш тарту турында) карар кабул итә.

3.6. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» подпунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карап тикшерү буенча Комиссия утырышы керемнәр, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән вакыт узган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

3.7. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» һәм «е» подпунктларында күрсәтелгән белдерүнамә, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карап тикшерелә.

3.8. Комиссия утырышы аңа карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу

турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә карап тикшерелүче дәүләт хезмәткәре яки дәүләт органында дәүләт хезмәте вазифасын биләгән граждан катнашында үткәрелә. Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләве турында дәүләт хезмәткәре яки граждан шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» һәм «е» подпунктлары нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерүнамәдә күрсәтә.

3.8.1. Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда дәүләт гражданлык хезмәткәреннән яки гражданиннан башка үткәрелә:

а) әгәр Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» һәм «е» подпунктларында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерүнамәдә дәүләт хезмәткәренең яки гражданның Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтелмәсә;

б) Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләгән, тиешле тәртиптә аның үткәрелү вакыты һәм урыны турында хәбәр алган дәүләт гражданлык хезмәткәре яки гражданин Комиссия утырышына килмәсәләр.

3.9. Комиссия утырышында дәүләт хезмәткәренең яки Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифасын биләгән гражданинның (алар ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка кертелгән мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карап тикшерелә.

3.10. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар Комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматларны таратырга хокуклы түгел.

3.11. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а» подпунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан 2009 елның 30 декабрендәге № ПУ-702 Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында нигезләмә нигезендә тапшырылган белешмәләрнең ышанычлы һәм тулы булуын билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан Нигезләмә нигезендә тапшырылган, әлеге пунктның “а” подпунктында аталган белешмәләрнең ышанычсыз һәм (яки) тулы булмавын билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.12. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а» подпунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлешен билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәмәвен билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлмәвенә юл куелмаска тиешлеген күрсәтергә яисә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы кулланырга киңәш итә.

3.13. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» подпунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга, әгәр дә әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифаи биләүгә яки коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирү;

б) гражданга, әгәр дә әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифаи биләүгә яки коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирмәү һәм бу рөхсәт бирмәүне нигезләү.

3.14. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» подпунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы

йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмавының сәбәбе объектив һәм игътибарга алырлык дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмавының сәбәбе нигезле түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмавының сәбәбе объектив түгел һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшырудан качу ысулы булып тора дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.15. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» подпунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) “Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкин булмаган шартларның объектив һәм игътибарга лаек булуын танырга;

б) “Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкин булмаган шартларның объектив булмавын һәм нигезсез булуын танырга. Бу очракта министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.15.1. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» подпунктының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт гражданлык хезмәткәре тарафыннан вазифаи вәкаләтләр үтәлгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы юклыгын танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан вазифаи вәкаләтләр үтәлгәндә шәхси кызыксынучанлыкның мәнфәгатьләр каршылыгына китерүен яки китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яки) министрга мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яки алар барлыкка килүне булдырмау буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәренең мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча таләпләрне үтәмәгән дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.16. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «в» подпунктында каралган мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия тиешле карарларның берсен кабул итә.

3.17. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «г» подпунктында каралган мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан “Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүгә контрольлек итү хакында” Федераль законның 3 статьясының 1 өлеше нигезендә тапшырылган мәгълүматларның ышанычлы һәм тулы булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан “Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүгә контрольлек итү хакында” Федераль законның 3 статьясының 1 өлеше нигезендә тапшырылган мәгълүматларның ышанычсыз һәм тулы булмавын танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә һәм (яки) чыгымнарны контрольдә тоту барышында алынган материалларны прокуратура органнарына һәм (яки), компетенцияләренә туры килгән башка дәүләт органнарына җибәрергә киңәш итә.

3.18. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «д» подпунктында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифасын биләгән гражданга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) аның тарафыннан, әгәр дә әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифаи биләүгә яки коммерциячел яки

коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкарылуга рөхсәт бирергә;

б) аның тарафыннан коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифаи биләүнең яки коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкарылу (хезмәтләр күрсәтүнең) "Коррупциягә каршы көрәш турында" Федераль законның 12 статьясындагы таләпләрне боза дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга күрсәтелгән шартлар турында прокуратура органнарына һәм хәбәр итүче оешмага җиткерү турында киңәш итә.

3.19. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «е» подпунктында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәреннән тормаган шартлар килеп чыгу белән аның хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү таләпләрен үтәү мөмкинлеген булмауның сәбәпле бәйләнеше булуын тану;

б) дәүләт хезмәткәреннән тормаган шартлар килеп чыгу белән аның хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү таләпләрен үтәү мөмкинлеген булмауның сәбәпле бәйләнеше булмавын тану;

3.20. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а», «б», «г», «д» и «е» подпунктларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, моңа нигезләр булган очракта, Комиссия шушы Нигезләмәнең 3.11 - 3.15.1 и 3.17 - 3.19 пунктларында күрсәтелгәннәрдән аермалы карар кабул итә ала. Мондый карарны кабул итү нигезләре һәм сәбәпләре Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

3.21. Комиссия карарларын үтәү өчен Министрлыкның норматив хокукый актлары проектлары, министрның карарлары яки йөкләмәләре әзерләнергә мөмкин, алар билгеләнгән тәртиптә карап тикшерү өчен министрга тапшырыла.

3.22. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Комиссия карарлары (әгәр Комиссия башкача карар кабул итмәсә) утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән, яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

3.23. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларны Комиссиянең утырышында катнашкан әгъзалары имзалый. Комиссия карарлары, шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» подпунктының икенче

абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерүдән кала, министр өчен киңәш итү рәвешендә була. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» подпунктының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карар мәҗбүри рәвешле була.

3.24. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышының датасы, утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының һәм башка затларның фамилиясе, исеме, аталарының исеме (булса);

б) аңа карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә карап тикшерелүче дәүләт хезмәткәренең фамилиясен, исемен, атасының исемен (булса), вазифасын күрсәтеп, Комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең формулировкасы;

в) дәүләт хезмәткәренә карата белдерелгән дәгъвалар, аларны нигезли торган материаллар;

г) дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның белдерелгән дәгъваларның асылына карата аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилиясе, исеме, аталарының исеме (булса) һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) Комиссия утырышын үткәрү өчен нигезне үз эченә алучы мәгълүмат чыганагы, мәгълүматның Министрлыкка килү датасы;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

3.25. Комиссия карары белән риза булмаган комиссия әгъзасы язмача рәвештә үз фикерен бәян итәргә хокуклы, ул Комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә беркетелергә һәм аның белән дәүләт хезмәткәре танышырга тиеш.

3.26. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе утырыш көненнән соң 7 көнлек срокта министрга, тулысынча яки аннан өземтә рәвешендә – дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары буенча – башка кызыксынган затларга җибәрелә.

3.27. Министр Комиссия утырышы беркетмәсен карап тикшерергә бурычлы һәм үз компетенциясе кысаларында дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турында карар кабул иткәндә һәм коррупциягә каршы көрәш оештыруның башка төрле мәсьәләләре буенча андагы киңәшләрне исәпкә алырга хокуклы. Комиссия киңәшләрен карап тикшерү һәм кабул ителгән карар турында министр язмача рәвештә аңа Комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән соң бер айлык срокта Комиссиягә хәбәр итә. Министрның карары Комиссиянең якын киләчәктәге утырышында игълан ителә һәм фикер алышуларсыз гына игътибарга алына.

3.28. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар гаеп билгеләре ачыкланган очракта, бу хактагы мәгълүмат, дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турында мәсьәләне хәл итү өчен, министрга тапшырыла.

3.29. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең административ хокук бозу билгеләрен яки җинаять составын үз эченә алучы гамәлләрне кылу (гамәл кылмавы) факты ачыкланган очракта, Комиссия рәисе күрсәтелгән гамәл кылыну (гамәл кылынмау) турындагы мәгълүматны һәм мондый фактны раслый торган документларны 3 көнлек срокта, ә кирәк булганда – кичекмәстән, хокук органнарына тапшырырга тиеш.

3.30. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яки аннан алынган өземтә аңа карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә карап тикшерелгән дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

3.31. Комиссия карарыннан алынган, Комиссия сәркатибенең имзасы һәм Министрлык мөһере белән таныкланган өземтә аңа карата Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» подпунктының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә карап тикшерелгән, Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифасын биләгән гражданинга имзалатып тапшырыла яки аның тарафыннан мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча, Комиссиянең тиешле утырышы үткәрелгән көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча, белдерүнамә белән заказлы хат итеп җибәрелә.

3.32. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документаль яктан тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырыш көне, вакыты һәм үткәрү урыны турында хәбәр итү, Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышында фикер алышу өчен тапшырыла

торган материаллар белән таныштыру Министрлыктагы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазифаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
____________№_________
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясе **составы**

**Комиссия рәисе:**

| | |
|---|---|
| Кыямов Алмаз Әхтәм улы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары |

**Комиссия рәисе урынбасары:**

| | |
|---|---|
| Галәүтдинов Зөлфәт Зәкиулла улы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының хокук идарәсе башлыгы |

**Комиссия сәркатибе:**

| | |
|---|---|
| Сабиров Камил Рөстәм улы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кадрлар бүлегенең әйдәп баручы консультанты, коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча вазыйфаи зат |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Алимбекова Лениза Фаик кызы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының матбугат сәркатибе, әйдәп баручы белгеч |
| Бадыйкова Эльвира Рамил кызы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының икътисад бүлеге мөдире |
| Булгаков Олег Михайлович | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының карамагындагы |

| | |
|---|---|
| | Иҗтимагый совет вәкиле, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләре берлеге» коммерциячел булмагае ширкәтнең башкарма директоры (килешү буенча) |
| Габделхаков<br>Альберт Рафаил улы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кадастр мөнәсәбәтләре бүлеге мөдире |
| Газизов<br>Ринат Марат улы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кадрлар бүлеге мөдире |
| Груздева<br>Кристина Сергеевна | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының икътисад бүлеге әйдәп баручы консультанты |
| Демидов<br>Анатолий Сергеевич | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт җирләрен нәтиҗәле файдалану бүлегенең әйдәп баручы консультанты |
| Зарипов<br>Радий Ринат улы | ФГБОУ ВО «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты»ның тарих һәм философия кафедрасы доценты, 41 нче урта гомумбелем бирү мәктәбенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары (килешү буенча) |
| Зубаков<br>Вячеслав Михайлович | АНО ВПО ЦРФ «Россия кооперация университеты»ның Казан кооператив институтының (филиал) икътисад һәи идарә кафедрасы доценты, икътисад фәннәре кандидаты (килешү буенча) |
| Мөбәрәков<br>Алмаз Газинур улы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының җир ресурслары идарәсенең җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге мөдире |
| Мусин<br>Фәрит Шаһит улы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының Ветераннар советы рәисе (килешү буенча) |
| Хәлимдаров | Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә |

| | |
|---|---|
| Тимур Рөстәм улы | каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең коррупциягә каршы мониторинг бүлегенең баш киңәшчесе (килешү буенча) |